# КАРАР

## Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Зур Әтрәч авыл җирлегенең Зур Әтрәч торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**13 ноябрь  2019 ел** **№ 1**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, 2019 елның 13 ноябрендә «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районыны Зур Әтрәч авыл җирлегенең Зур Әтрәч торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлар, балачактан инвалидлардан тыш, 2020 елда 1200 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм аннан алынган акчаларны  җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен, түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлдерүгә сез риза буласызмы:

- Зур  Әтрәч авылында авыл эчендәге юлларны төзекләндерү өчен вак таш сатып алу;
- Зур  Әтрәч авылында лампалар, урам яктырткычлары һәм махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру;
- Зур  Әтрәч авылында чишмәне төзекләндерү;
- Зур  Әтрәч авылында күл территориясен төзекләндерү;
- Зур  Әтрәч авылында Тукай урамындагы балалар мәйданчыгын койма белән әйләндереп алу;
- Зур  Әтрәч авылында һәлак булган сугышчыларга куелган обелиск территориясен төзекләндерү?».

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булучы җыенда катнашучылар исемлегенә 211 кеше кертелде, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны - 121 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 120 кеше тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 1 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Зур Әтрәч авыл җирлегенең Зур Әтрәч торак пунктында гражданнар җыенын узган дип таныргa, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес дип таныргa.

2. Әлеге мәсьәлә буенча: «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районыны Зур Әтрәч авыл җирлегенең Зур Әтрәч торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлар, балачактан инвалидлардан тыш, 2020 елда 1200 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм аннан алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен, түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлдерүгә сез риза буласызмы:

- Зур Әтрәч авылында авыл эчендәге юлларны төзекләндерү өчен вак таш сатып алу;
- Зур Әтрәч авылында лампалар, урам яктырткычлары һәм махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру;
- Зур Әтрәч авылында чишмәне төзекләндерү;
- Зур Әтрәч авылында күл территориясен төзекләндерү;

- Зур Әтрәч авылында Тукай урамындагы балалар мәйданчыгын койма белән әйләндереп алу;
- Зур Әтрәч авылында һәлак булган сугышчыларга куелган обелиск территориясен төзекләндерү?».

«РИЗА» «КАРШЫ»

карар кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълъмат рәсми порталында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

**Халык җыенында**
**рәислек итүче** **И.Ш. Юнусов**

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Зур Әтрәч авыл җирлеге башлыгы** **И.Ш. Юнусов**